ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 июль 2018 ел № 3844

Башкарма комитетның 2018 елның 27 мартындагы 1631 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 маддәсе, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2013 елның 23 апрелендәге 275 нче карары, Яр Чаллы шәһәре Уставы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 27 мартындагы 1631 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.3 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үз эшчәнлеген Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә гамәлгә ашыра торган юридик затка карата 294-ФЗ санлы Федераль законның 11 һәм 12 маддәләрендә каралган һәр тикшерүне үткәрү срогы юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структура бүлекчәсе буенча аерым билгеләнә, шул ук вакытта тикшерү үткәрү срогы алтмыш эш көненнән дә артык булырга тиеш түгел.»;

2) 2.5.3 пунктның 22 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Планнан тыш кучмә тикшерү үткәрү турында (үткәрү нигезләре 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсендәге 2 бүлекнең 2 пунктында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүдән тыш) юридик затка, шәхси эшмәкәргә муниципаль торак контроле органы тарафыннан аны үткәрә башлауга егерме дүрт сәгатьтән ким булмаган вакыт эчендә, теләсә нинди юл белән хәбәр җибәрелә, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ аша юридик зат, шәхси эшмәкәрнең электрон почта адресына белдерү кәгазе җибәрү юлы белән, әгәр андый адрес юридик затларның бердәм

дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан элек муниципаль торак контроле органына җибәрелгән булса.»;

3) 5.2.2.5 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында (үткәрү нигезләре 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсендәге 2 бүлекнең 2 пунктында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүдән тыш) юридик затка, шәхси эшмәкәргә җаваплы башкаручы тарафыннан аны үткәрә башлауга егерме дүрт сәгатьтән ким булмаган вакыт эчендә, теләсә нинди юл белән хәбәр җибәрелә, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ аша юридик зат, шәхси эшмәкәрнең электрон почта адресына белдерү кәгазе җибәрү юлы белән, әгәр андый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан элек муниципаль торак контроле органына җибәрелгән булса.»;

4) 5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү тәртибен билгеләүче 294-ФЗ санлы Федераль закон нигезләмәләре производствода аварияләр, бәхетсезлек очраклары килеп чыгу, кешеләрнең, хайваннарның һәм үсемлекләрнең йогышлы һәм массакүләм йогышлы булмаган авырулары (агуланулары, зарарланулары), әйләнә-тирә мохиткә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә зыян китерү сәбәпләре тикшерелгән очракта кулланылмый.»;

5) 7.9 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шикаятькә җавап, муниципаль торак контроле органына яки вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә һәм муниципаль торак контроле органына яки вазыйфаи затка язма рәвештә кергән шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә. Моннан тыш, муниципаль торак контроле органына яки вазыйфаи затка кергән билгесез даирә затлары мәнфәгатьләренә кагыла торган тәкъдимнән, гаризадан яки шикаятьтән гыйбарәт мөрәҗәгатькә, аерым алганда билгесез даирә затларына карата чыгарылган суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән суд карарына шикаять бирү тәртибе аңлатылган җавап «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ санлы Федераль законынның 6 маддәсенең 2 бүлегендәге таләпләрен үтәп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль торак контроле органы мәгълүматларының рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин